СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

НУРЛАТ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА НУРЛАТСКОГО РАЙОНА.

*25 сентябрь, 1998 ел.*
*ҖОМГА*

*Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга.* | *№ 109 (8266)* | *Бәясе билгеләнгәнчә*

# БЕРЛӘШТЕРЕЛГӘН СОВЕТ КАРАР ЧЫГАРДЫ...



***Инде хәбәр ителгәнчә, сишәмбе көнне халык депутатларының Нурлат берләштерелгән Советының чираттагы унҗиденче сессиясе булды. Анда депутатлардан тыш, җирле үзидарә Советлары рәисләре, предприятие, оешма һәм учреждение җитәкчеләре, мәктәп директорлары һәм мәктәпкәчә яшьтәге балалар учреждениеләре мөдирләре дә чакырылган иде.***

Сессиянең көн тәртибе башта ук ачыкланды. Анда иң элек Нурлат шәһәр һәм район эчке эшләр бүлеге подразделениеләренең быел сигез айдагы эше турындагы хисабы кертелде. Советның еллык эш планына кертелгән бу мәсьәлә сессиягә ашык - пошык кына әзерләнмәгән иде. Берләштерелгән Совет рәисе **Ф.С. СИБАГАТУЛЛИН** әле 1997 елда ук бер сессиядә моннан ары төрле тармак отчетларын, анда да беренчел җитәкчеләрнең генә түгел, ә төрле подразделениеләр башлыкларының да хисабын тыңлауны практикага кертү кирәклеге турында тәкъдим белән чыккан иде. Һәм менә бу юлы сессиядә шәһәр һәм район эчке эшләр бүлеге башлыгының криминаль милиция буенча урынбасары **В.Л. Гаврилов** һәм бүлек начальниклары - участок инспекторлары белән җитәкчелек итү буенча **Ф.Т.Дашкин,** юл хәрәкәте иминлеге буенча дәүләт инспекциясеннән **Х.В.Әюпов,** балигъ булмаганнар арасында җинаятьчелекне кисәтү буенча **Н.Г.Корбанов** чыгыш ясадылар. В.Л. Гавриловның отчетын Совет рәисе тәнкыйть күзлегеннән чыгып бәяләде, чыгыш ясаучыларга бирелгән күпсанлы сорауларның да иясе башлыча ул иде, шуңа күрә бүлек башлыкларына тулы отчет тотарга туры килде дияргә мөмкин. Ә сораулар күптөрле характерда булды: тиешле техник ныгытылыш, хезмәтне саклау тәэмин ителмәгән, матди байлыкларның сакланышы рәтләп оештырылмаган, нәтиҗәдә алардан терлек, авторезина һәм башкалар урланган предприятие, хуҗалык җитәкчеләре һәм матди җаваплы кешеләренә карата нинди чаралар күрелгән, кайсысы җавапка тартылган, бүлек башлыклары үзләре хезмәт коллективларында шушы мәсьәләләр карала торган җыелышларда еш булалармы, астан гына аракы сатып ятучылар ни өчен һаман да җәзасыз кала киләләр?... Аннары, балигъ булмаганнар арасында хокук бозуларны кисәтү бүлегендә (ОППН) наркоманлыкка хирысланган бары 5 үсмер исәптә тора, ә бу чын хәлне чагылдырамы соң? Сессиядә шушы һәм башка сорауларга җавап табу йөзеннән күп сүз булды. Шәһәр һәм район эчке эш-



ләр бүлеге начальнигы **В.В.Иванов**ның чыгышы гаять конкрет, ачык һәм объектив төстә иде. Мәгълүматлылык өчен аның чыгышыннан берничә сан гына китереп үтик. Сигез айда шәһәрдә һәм районда 346 җинаять эшләнгән һәм бу узган елның шул чорындагыдан 28,1 процентка күбрәк. Дөрес, авыр җинаятьләрнең тоткан урыны кими төшкән. Шул ук вакытта җинаятьләрнең ачылыш дәрәҗәсе түбән булып кала бирә. Җинаятьләр саны башлыча көчләү, авыр тән җәрәхәтләре ясау, урлау, шулай ук юл - транспорт җинаятьләре, автомототранспорт урлаулар исәбенә арткан. Бүлекнең төп службалары эшен анализлап һәм бәяләп, шулай ук кадрлар проблемасына тукталып, милиция начальнигы гражданнарның мөлкәт һәм шәхес иминлеген тәэмин итү, районга Татарстанның һәм Самараның зур шәһәрләреннән оешкан җинаятьчел төркемнәрнең үтеп керүенә юл куймауны, оператив - эзләнү эшчәнлеген камилләштерү, икътисад өлкәсендәге җинаятьчелек белән көрәшне активлаштыру, җинаятьчелекне, бигрәк тә яшүсмерләр арасындагысын кисәтү, шәхси составның һөнәри әзерлеген яхшыртуны төп бурычлар буларак билгеләп үтте. Наркотикларның законсыз әйләнеше кебек мәсьәлә дә читләтеп үтелмәде. Сүз дә юк, бу проблема белән көч органнары гына түгел, ә бөтен җәмгыять шөгыльләнергә тиеш.

Нурлат эчке эшләр бүлегенең личный составы һөнәри, мораль һәм физик яктан нигездә әзерлекле һәм үз алларына куелган бурычны башкарып чыгарга сәләтле.

Докладлар буенча фикер алышуда шәһәр һәм район прокуроры **А.П.Евграфов** чыгыш ясады. Прокурор була-



рак, мине иң элек дежур службаның һәм участок инспекторлары эшенең оештырылуы борчый, диде ул. Бусы, бер. Уголовный розыск хезмәте оештырылуның озакка сузылуы - икенче бер проблема. Наркоманлыкның үсүе һәм венерик авыруларның таралуы - өченче борчыган нәрсә. Дүртенчедән, прокурор юл хәрәкәте иминлеге мәсьәләсендә хәлне "юллардагы сугыш" дип бәяләде һәм бу юнәлештә конкрет чаралар күрергә тәкъдим итте. Район матбугаты һәм милициясенә тыгыз бәйләнештә эшләргә кирәк дип искәртергә дә онытмады прокурор. (Анысына килгәндә, без андый хезмәттәшлеккә һәрчак әзер, профессионал авторларга карата һәрчак хөрмәт белән карыйбыз һәм хезмәттәшлектән дә, мәгълүматтан да баш тартканыбыз юк).

Депутатлардан бу мәсьәлә буенча фикер алышуда **А.И.Савинов** чыгыш ясады. Шуннан соң тиешле карар бертавыштан һәм үзгәртүләрсез кабул ителде.

Чираттагы отчет район электр элемтәсе узелы начальнигы **Р.Ә. Җиһаншин**ныкы иде.



Аның районда элемтә эшенең торышы турындагы белдерүен бик игътибар белән тыңладылар, чөнки залдагы һәркем күпмедер дәрәҗәдә шунда абонент булып тора бит. 1998 елда шәһәрдә 262, авыл җирендә 72 яңа телефон куелган. Коллективның кабель линияләрен реконструкцияләү, кабель канализациясе төзү, авыллардагы станцияләрдә яңа аккумуляторлар монтажлау буенча башкарган эшләре турында сөйләп, Р.Ә. Җиһаншин төп проблемаларны, алар арасында иң мөһиме 3 мең номерлык яңа автомат телефон станциясен монтажлау икәнлеген билгеләп үтте. Элемтә челтәрен үстерүне тоткарлаучы сәбәпләрдән хуҗалыкларның инде биш - алты ел буе җыелып килә торган бурычлары әйтелде. Элемтә узелы башлыгына да сессиядә рәислек итүченең, шулай ук депутат Р.Ш.Хафизовның кайбер сорауларына җавап бирергә туры килде. Ахыр чиктә бу мәсьәләгә киләсе елның беренче кварталында кабат әйләнеп кайтырга, районга элемтә министрын да чакырырга дигән карарга киленде.

(Ахыры 2нче биттә).

## ТӨРЛЕ ЯКТАН, ТӨРЛЕ КҮЗЛЕКТӘН

### ТЕЛЕФОН ШАЛТЫРАДЫ...

***Нурлат район электр элемтәсе узелы коллективы Өлкәннәр көне уңае белән бер игелекле эш башлады.*** Элемтәчеләр К.Маркс проспектындагы 42 фатирлы ветераннар йортына телефон үткәрүгә керештеләр. Бүген монда 20дән артык нокта урнаштырылган инде. Алар барлык эшләрен ай ахырына тәгәлләргә ниятлиләр.

### ЛИФТ ЭШЛИ БАШЛАДЫ

***Шушы көннәрдә район үзәк хастаханә поликлиникасында лифт эшли башлады.*** Лифт эшләтү проектта башта ук каралган иде, әмма аны җибәрү быел гына мөмкин булды. Аны эшләтү өчен әзерлекле белгеч тә кирәк иде, документлар артыннан да күп йөрергә туры килде - тау - техник инспекциясе лифтка карата бик таләпчән бит. Барлык шушы мәшәкатьләрне хәл кылу гына да елга якын вакытны алды.

Лифт кабинасы нигездә йөкләр ташу, һәм бик кирәк булган очракта кайбер каты авыруларны төшерү - менгерү өчен каралган. Лифтны махсус кеше генә эшләтәчәк.

### ТҮЛӘҮ КИМЕМӘЯЧӘК

***"Сентябрь аена җылылык өчен түләү кимегән. Ары таба гел шул күләм генә калмый микән?"***

Газета укучыларыбызның бу соравын без Нурлат җылылык челтәрләре предприятиесенә юлладык. Аннан түбәндәге җавапны алдык:

"Кулланучыларның өмете бушка, түләү кимемәячәк. Сентябрь аенда без ТР Министрлар кабинетының 30.06.97 елда кабул ителгән 530нчы карары нигезендә узган җылылык сезоны нәтиҗәләре буенча (әлбәттә, тиешле коэффициентлар нигезендә) кулланучылар белән исәп - хисап ясарга тиешбез. Бу хисап кулланучы файдасына һәм киресенчә дә булырга мөмкин. Быелгы нәтиҗәләр буенча без кулланучы каршында бераз әҗәтле калганбыз, шуңа сентябрьгә түләү киметелде. Ары таба җылылык өчен түләү тариф нигезендә булачак."

### ҮЗ ШИКӘРЕБЕЗ ЧЫГА

Тиздән кибетләргә Татарстан шикәре чыгачак. Сезоннар арасы тәмамланды һәм республикада өч шикәр заводы чөгендер эшкәртә башлады. 22 сентябрьдә инде алар үз продукцияләрен тиешенчә бүлгәләп җибәрә башлаячаклар. 17 сентябрьдә куллану базарын тотрыклыландыру буенча республика оператив штабы утырышында авыл хуҗалыгы һәм азык - төлек министры Валерий Васильев шуны хәбәр итте. Иң мөһиме - Хөкүмәтнең чимал һәм шикәр ташу өчен транспорт белән ярдәм итүе кирәк.

Вице - премьер Адилә Конюшева тагын бер күңелле яңалык әйтте: республикага зур күләмдә тоз, үсемлек мае, дөге килә. Базарларда бу товарлар әлегә кыйммәт. һәм, кызганычка каршы, бераз төшә башлау тенденциясе күренүгә , долларның артуы уңаеннан яңадан кыйммәтчелек башланды, диде А.Конюшева. Шуның белән бергә, күптән түгел Хөкүмәтнең бәяләрне көйләү турындагы карары эшкуарларда төрле мөнәсәбәт тудырды: чыгымнар югары, аларны билгеле бер сәүдә өстәмәсе белән генә каплап булмый - таможня пошлиналары үзләре генә дә ни тора! Шушы уңайдан штаб рәисе, Премьер - министр Рөстәм Миңнеханов, карар - катып калган нәрсә түгел, аңа вакыйгаларның үсешенә бәйле рәвештә төзәтмәләр кертеп булачак, диде . Салым органнарына бу проблеманы өйрәнергә кушылды.

**("Ватаным Татарстан" нан.)**

### ТУҢГА СӨРҮНЕ АШЫКТЫРАСЫ

***Саннарның беренче баганасы - 23 сентябрьгә туңга сөрү планының үтәлеше (процентларда), икенчесе - соңгы бер көндә сөрелгән, өченчесе - шул исәптән бер тракторга туры килгән мәйдан (гектарларда).***

| | | | |
|---|---|---|---|
| "Агрохимсервис" ярд.хуҗ. | 100 | 30 | 5 |
| "Дуслык" | 99 | - | - |
| "Лесная Поляна" | 92 | 15 | 8 |
| Синдряков исем. | 91 | 80 | 8 |
| "Сөлчә" | 89 | 25 | 12 |
| Сөт - май комб. ярд. хуҗ. | 89 | 5 | 5 |
| "Төрнәс" | 84 | 10 | 3 |
| М.Җәлил исем. | 83 | 50 | 10 |
| "Игенче" | 83 | 30 | 6 |
| "Киекле" | 81 | 100 | 7 |
| "Үрнәк" | 80 | 35 | 12 |
| "Рассвет" | 78 | 50 | 5 |
| "Чулпан" | 76 | 40 | 8 |
| "Кондырча" | 73 | 40 | 10 |
| Нефтебаза ярд. хуҗ. | 72 | 44 | 15 |
| "Комбайн" | 72 | 20 | 7 |
| "Заветы Ильича" | 71 | 15 | 8 |
| РСУ ярд. хуҗ. | 65 | 72 | 12 |
| "Таң" | 65 | 15 | 5 |
| "Өмет" агрофирмасы | 64 | 80 | 13 |
| Шикәр заводы ярд. хуҗ. | 62 | 20 | 5 |
| "Алга" | 60 | 40 | 8 |
| "Татарстан" | 59 | 72 | 6 |
| "Чирмешән" агрофирмасы | 58 | 13 | 4 |
| Хафизов исем. | 52 | 25 | 8 |
| **Район буенча** | **72** | **926** | **8** |

# БЕРЛӘШТЕРЕЛГӘН СОВЕТ КАРАР ЧЫГАРДЫ...



Көн тәртибендәге чираттагы мәсьәлә буенча район мәгариф бүлеге мөдире **Г.Ә. Юнысов** чыгыш ясады. "Район мәгариф бүлегенең, педагогик коллективларының һәм мәгариф учреждениеләренең хәзерге этаптагы эше турында" халык депутатларының район Советы карарының үтәлеше турындагы информация бераз шомартылган кебегрәк тоелды һәм бу Ф.С.Сибагатуллинның тиешле реакциясенә сәбәп булды да: нәрсә, мәктәпләрдә бүген проблемалар яки җитешсезлекләр юкмы әллә? Шунда ук сораулар да яуды: ничә укучы ОППНда каләм очына алынган, кызларның күпмесе тәмәке тарта, ник стадион начар файдаланыла (балаларның сәламәтлеге турында кайгырту иң элек спортны үстерү дигән сүз бит һәм 1998-1999 уку елының шушы билге астында узуы юкка түгел), мәктәпләрдә яхшы спорт мәйданчыклары юк, мәктәп янында яшелчә үстерү участоклары булырга тиешме? һ.б. Бу урында депутат А.И.Савинов үзенең мәктәпләрдә балаларны кайнар аш белән тәэмин итүне оештыру, мәктәп медпунктларын медикаментлар белән тәэмин итү мәсьәләләрендә борчылуын әйтеп, милли мәгариф проблемаларына да кагылды, Нурлатта татар мәктәбе ачу мәсьәләсен каpарга тәкъдим итте.

*(Ахыры. Башы 1нче биттә).*

Нурлат шәһәре территориясендә бәяләрне комплексны зоналаштыру турында хәбәр итү өчен сүз район җир ресурслары комитеты рәисе **В.А.Шиловка** бирелде. Ул бәяләү зоналары буенча җир салымнары ставкаларын арттыру һәм уртача җир салымнары ставкасын дифференциацияләү коэффициентын депутатлар игътибарына тәкъдим итте. Әлеге коэффициентлар Татарстан җир төзелеше проект - тикшерену предприятиеләренең җирләргә дәүләт бәясе билгеләү агентлыгы белгечләре тарафыннан 1997 елда эшләнгән. Коэффициент кабул итүнең төп сәбәпләре итеп В.А.Шилов салым салу өлкәсендә җирле бюджетның формалашуын, җирне милек буларак тапшырганда мөнәсәбәтләрне көйләү, җиргә коллектив - өлеш мөнәсәбәте урнаштыру, җирне мирас буларак тапшыру, җир участогын закладка салган өчен банк кредиты алу һәм бүләк итүне атады. Шулай итеп, Нурлат зоналарга бүленәчәк, һәм салым җыю шушы нигездә башкарылачак. Әмма тәҗрибәсез укучыбыз да салым күләменең шәһәр үзәгендә бер төрле, ә читендә икенче төрле булачагын чамалый торгандыр. Шунысын да искәртеп үтик - бу мәсьәлә алдан да каралган иде һәм безнең депутатлар чираттагы сессияләрнең берсендә моңа кабат әйләнеп кайтырлар әле. Коэффициентлар хәзергә кабул ителмәде. Депутатларга җир участокларыннан файдаланган һәм даими файдалану өчен бирелгәндә бер генә тапкыр түләнә торган салымның күләмен хәл итү мәсьәләсе тәкъдим ителгән иде. Бу очракта физик һәм юридик затлар, гражданнар һәм оешмалар аерым - аерым карала. Бер сүз белән әйткәндә, монда нинди дә булса объект төзергә теләге булганнарга үз мәнфәгатьләрен кайгыртырга туры килә. Мәсәлән, гараж һәм сарайлар төзү өчен участоклар бүлгәндә шәхси затлардан бер квадрат метр өчен 6 сум, ә сәүдә максатлары өчен булганда (киләчәк керемне дә күздә тотып!) инде 30 сум алыначак. Юридик затлар производство һәм коммерция максатларында объектлар төзегәндә ике тапкыр кимрәк - 15 сум түләячәкләр. Депутатларга чагыштырып карарга уңайлы булсын өчен җир ресурслары комитеты таблица да хәзерләгән: Казанда, Яр Чаллыда, Чистайда күпме түләүләрен күрсәткән. Нурлатта кимрәк чыга. Шунысын да әйтергә кирәк, бу мәсьәлә һич тә күктән төшмәде - ТРның "Җир өчен түләү турында"гы Законын (7нче маддә) кара. Кабул ителгән карар инде гамәлгә керде.

Аннан соң сессия **Ю.А. Муракаевны** коммуналь милек белән идарә итү буенча комитет рәисе итеп билгеләде һәм үзенең карары белән район дәүләт ветберләшмәсе, ветеринар баклабораториясе, дәүләт орлык инспекциясе һәм күпьеллык үләннәр буенча орлыкчылык станциясенең күчемсез милеген коммуналь милеккә тапшырды. Бу адым биналарны саклау һәм ремонтлау, алардан файдалануны яхшырту максатларын күздә тотып ясалды.

***

Сессия ябылганнан соң **Ф.С.Сибагатуллин** барлык җитәкчеләргә алда торган Өлкәннәр көнен онытмауларын үтенеп мөрәҗәгать итте. Финанс хәлләре никадәр генә катлаулы булмасын, ветераннарны чәй табынына дәшү һәм аларга күчтәнәчләр өләшү кулдан килмәслек эш түгел. Ул шулай ук авыл халкына газ үткәргән өчен түләүләрне мөмкин булган кадәр тизрәк башкаруларын бик тә мөһим икәнлеген аңлатуны сорады. Акчага бик тә кытлык икәнен беләбез, әмма торбаларның да бәясе үсә, ә яңа елдан соң алар тагын да кыйммәтрәк булачак. Утын яки күмер сатып алу һәм аны өйгә кайтару да арзанга төшми бит. Бюджеттагыларга хезмәт хакы түләү мәсьәләсе, диде шәһәр һәм район хакимияте башлыгы, кибетләрдә аракы сатылу һәм Нурлат шикәр заводында продукция җитештерелү дәрәҗәсенә бәйле.

**Т.НАЗАРОВ.**
**Н.АЗИЗОВ фотолары.**

## КОЛЛЕКТИВ ҺӘМ АНЫҢ ЭШЕ

# КИЛӘЧӘКТӘ ДӘ ЯШӘР ӨЧЕН

***"Татнефтедор" акционерлык җәмгыятенең Нурлат автоюллар идарәсе (НУАД) икенче ел инде мөстәкыйльлек шартларында яши. Элек "Нурлатнефть" НГДУсы канаты астына сыенып көн күргән оешма мөстәкыйльлекнең бар ягы - рәхәтмихнәтеннән чирканыч алырга өлгерде инде. 135 кешене берләштергән коллективның быелгы сезонда да эшләре кызу булды***

НУАД элегрәк нефть объектларына юллар салу, мәйданчыклар төзү буенча махсуслашкан булса да, аның эшчәнлеге бу кысалар белән генә чикләнмәде, билгеле. Соңгы вакытта, структур үзгәреш кичергәч, аның эш күләмендә шәһәр эчендә юллар түшәү, зур трассаларда юллар салу, поселокара юлларны тәртиптә тоту кебек заказлар торган саен күбрәк урын ала баралар. Быел да аның эш планында Нурлат - Әлмәт, Чирмешән юлларына капиталь ремонт үткәрү, Биккол - Фома, Самара һәм шәһәр эчендәге әйләнеп узу юлларын түшәү кебек мөһим объектлар бар иде һәм идарә аларны уңышлы үтәде. Гомумән, НУАДның быелгы эш күрсәткечләре сөенерлек.Моның өчен быелның 8 аенда ул башкарган эш күләмен узган ел белән чагыштыру гына да җитә. Мәсәлән, былтыр бу чорда 33,3 мең тонна асфальт җитештерелсә, быел ул сан 36,8 мең тонна тәшкил итә. Узган ел 1нче сентябрьгә 11719,9 мең сумлык хезмәт күрсәтелсә, быелгысы 14384, 3 мең сум булды. Бүгенге саннардан чыгып, ел дәвамында алдагы елга карата үсеш 19,3 процент булыр, дип фараз ителә. Килешегез: бу начар күрсәткеч түгел!

Ә бит сезонны шактый авыр хәлдә башлап китәргә туры килгән иде аларга. Иң әүвәл, язның соң килүе нәтиҗәсендә, эшкә соңрак тотындылар.

- Узган ел 19 апрельдә ремонтны тәмамлап, асфальт түши башлаган идек, ә быел 22 апрельдә ремонтка тотындык кына,- дип искә алалар юлчылар. Эшнең 20 көнгә соң башлануы гомуми күләмдә үзен сиздерер дип борчылып та алалар. Икенчедән, коллектив сезонга инерт материалларны тиешенчә әзерләп керешә алмый, вак таш, ком,ком - гравий катнашмасы, минераль порошок узган елгы күләмнең 50 проценты дәрәҗәсендә генә көйләнгән була. Сәбәбе - АҖ акча бүлә алмау сәбәпле, идарә тимер юл станциясенә шактый зур суммада бурычлы була, йөк ташу туктатыла. Бары Куйбышев тимер юл бүлеге начальнигы А.С. Левченко белән Нурлат җирендә үткән очрашудан соң, бу хәлләргә район хакимияте алынгач кына материал ташуга юл ачыла. Шулай итеп, юл төзүчеләргә җәйге айда юл эшләре белән бергә материал табу мәшәкатен параллель алып барырга туры килә. Материаллар ташкыны исә июнь аеннан башлана һәм өч айда НУАДлыларга 50 мең тонна, ягъни 835 вагон йөк бушатырга туры килә! Чималны вагоннан туп - туры эш объектларына ташыган чаклар, эшчеләрнең караңгы төнгәчә ике объектта да токкарланган вакытлары еш була һәм, иң мөһиме, берәү дә зарланмый, ыңгырашмый, баш тартмый. (Хәтерләсәгез, элекке таркалып бетә язган НУАД бит бу!) Шулай, коллектив үз яшәешен саклар өчен эш күләмен дә, җитештерүнең сыйфатын да яхшыртырга кирәклеген әйбәт аңлый. Бу мәсьәләдә идарә начальнигы Һ.Х. Садыйков юл участогы начальнигы М.М.Вәлиев, производство - техник бүлек начальнигы В.С. Иванова, АТЦ начальнигы Р.Мостафин,мастер Р.С.Гафуровны үзенең беренче ярдәмчеләре итеп саный.

Горурланырлык вакыйгалары да бар икән. Август аенда "Татнефтедор" АҖсенә караган 5 автомобиль юллар идарәсе арасында түшәлгән асфальтның сыйфатына конкурс үтә. Махсус комиссия салынган юллардан асфальтны анализга ала, башка параметрларны да карый һәм берсүзсез беренчелекне Нурлат автоюллар идарәсенә бирергә дип карар кыла.Мастер Виктор Петрович Багаев кул астында эшләүче асфальт түшәүче А.М.Зевакин, каток машинистлары Н.Л.Левинов һәм И.А. Яллинның, юл эшчеләренең чираттагы зур уңышы була бу. Нефтьчеләрнең һөнәри бәйрәме алдыннан гына "Татнефтедор" АҖ карары нигезендә профессиональ конкурста җиңүче дип табылган 12 кешегә - юл мастерына, асфальт түшәүчеләргә, асфальт - бетон әзерләүчеләргә Мактау грамоталары һәм акчалата премияләр кайтты. Чираттагы диюебез тикмәгә түгел, чөнки түшәлгән юлларның һәр 2 мең квадрат метрыннан шундый анализ алына һәм аның беркайчан да сыйфатсыз дип табылганы юк икән әле! Һади Харисович моңа тагын бер дәлил китерде. Узган ел алар түшәгән Камышлы - Егоркино, Аэропорт, Киекле фермасына юлларны комиссия бер карауда, гарантияле хаттан башка кабул итә һәм бу да гайре гадәти хәл түгел!



Н.АЗИЗОВ фотосы.

Сүз дә юк, НУАД юллары дөнья стандарты дәрәҗәсендә диган сүз түгел әле бу. Аның өчен күп шартлар, әйтик, сыйфатлы чимал, тиешле техника да кирәк. Техникага килгәндә, НУАДта юл төзүнең иң примитив, иң гади җайланмалары тупланган. Юл түшәүдә, мәсәлән, иң мөһим таләп асфальт салу җайланмасына төшә. Ә биредә аның өр - яңа дигәне дә моннан 3 ел элек алынган һәм ул бүгенге шартларда китмән чоры техникасын хәтерләтә. Тыгызлагычлар кирәк. Аның биредәге төсле 8 тонналысы түгел, нәкъ менә күп җирдә кулланыла һәм бәяләнә торган 16 тонналысы. Хәзер элеккечә дәүләт юл фондыннан андый кыйммәтле техниканы күрермен димә. Узган ел Т - 170 бульдозеры, 1 автокран һәм төягеч алуларына быел да сөенеп торалар әле. Хәзер үз мәшәкатеңне үзең хәл итәр чак. Әнә узган ел үз көчләре белән ике иске асфальт заводын сүтеп, яңа завод төзегәннәр. Элек пар белән эшләтелә торган заводны май белән эшләтүгә күчергәннәр, шулай итеп, продукциянең үзкыйммәтен арзанайтуга ирешкәннәр. Асфальт чыгару мөмкинлеге һәм аның сыйфаты канәгатьләндерүдән узган бу иске объектлар урынына хәзер тәүлеклек эшләп чыгару куәте 400әр тонна булган ике завод гамәлдә. Әмма соңгысы идеаль шартларда гына мөмкин. Шуннан инде завод өчен инерт материаллар әзерләү мәйданчыгын бетонлау, ябык түбәле складлар булдыру зарурлыгы көн каршына килеп баса. Алар, мәгълүм ки, барысы да акчага бәйле, ә түләмәүчелек чире НУАДны да читләтеп үтми. Быелның 1 сентябренә аларга 5 млн. сум дебиторлык бурычы бар, шуның700 меңе - крестьян хуҗалыклары ассоциацияләреннән (димәк, тиз генә алам димә!). Шуңа карамастан, идарә беркайчан да авыл проблемасына йөз чөереп карамый. Шефлары "Киекле" КХАсына ярдәмне әйтәсе дә юк, әледән - әле теге яки бу үтенеч белән ишек шакыган башка хуҗалык җитәкчеләре дә буш кул белән сирәк китәләр. Бу - үтә байлыктан түгел, бу - авылның чарасызлыгын аңлаудан. Юкса, НУАД үзе дә әнә 30 машина өчен җылы стоянка, 2 мең куб. метрлык битум саклагыч төзү белән мәшгуль, үлчәү хуҗалыгын тәртипкә китерә. Хезмәт хакын да чагыштырмача даими бирергә тырыша, җирле салымнарны, пенсия фондына кертемнәрне дә еллар буе сузмый. Ә боларның һәммәсен алып бару җиңел түгел. Идарәдә ныклы дисциплина, катнаш һөнәр өйрәнү төп шарт итеп куелган. Грейдерчы - катокка утыра, каток машинисты - асфальт түшәүчене алыштыра ала. Заманасы шундый - җитештерү өзлексез булырга тиеш. Ни дисәң дә, елына ничә тапкыр кыскарту җиле исеп ала НУАД янәшәсеннән һәм аңардан иң булдыклылар, иң эшчәннәр генә саклана ала.

**Юлчылар өчен җитештерү сезоны ахырына таба бара. Күзгә өзеклекләргә кадәр тизрәк ремонтлыйсы, асфальт түшисе, мәйданчык саласы, дип тырышалар НУАДта. Чөнки беләләр: җитештерү күләме булса гына коллектив яши, ә Нурлат автоюллар идарәсе әле яшәргә дә яшәргә җыена.**

**С.ХӘЙРУЛЛИНА.**

# БӘЯЛӘР БИК СИКЕРМӘСЕН

***Татарстан Республикасы халкын беренче чиратта кирәкле товарлар белән өзлексез тәэмин итү, бәяләрнең үсүен булдырмау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Бәяләрне (тарифларны) дәүләт җайга салуы чаралары турында"гы 1995 ел, 6 июньдәге 343 номерлы карарына туры китереп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты 1998 елның 14 сентябрендә 525 нче номерлы карар чыгарды.***

***Анда 1998 елның 17 сентябреннән:***

***1 номерлы кушымтага туры китереп, барлык рәвештәге милекле предприятиеләр һәм оешмалар өчен икмәккә, икмәк - күмәч әйберләренә, манный ярмасына, сөт һәм сөт продуктларына көйләнүле чик ваклап сату бәяләрен;***

***2 номерлы кушымтага туры китереп, онга, манный ярмасына күпләп сату бәяләрен расларга һәм гамәлгә кертергә;***

***2. Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль бензины, дизель ягулыгы һәм башка ягулык - майлау материаллары, 30 процентка кадәр күләмдә тәэмин итү - сату өстәмәсе кулланып, җитештерүче заводларның күпләп сату (яки сатып алу бәяләре) буенча сатыла, дип билгеләргә;***

***3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Ягулык - майлау материалларына бәяләр турында"гы 1997 ел, 1 апрельдәге 276 нчы карарының А - 72, А - 76 автомобиль бензинына һәм дизель ягулыгына чик бәяләр билгеләнгән өлешендәге 1 һәм 2 пунктлары үзенең көчен югалткан, дип санарга, диелә.***

**1 КУШЫМТА**

## АЗЫК - ТӨЛЕК ТОВАРЛАРЫНА КҮПЛӘП ҺӘМ ВАКЛАП САТУНЫҢ КӨЙЛӘНҮЛЕ БӘЯЛӘРЕНЕҢ ЧИК КҮЛӘМНӘРЕ (СУМНАРДА ҺӘМ ТИЕННӘРДӘ)

| Исеме | Үлчәү берәмлеге | Өстәмә кыйммәт салымлы күпләп сату бәясе | Өстәмә кыйммәт салымлы һәм сәүдә өстәмәле ваклап сату бәясе |
|---|---|---|---|
| **Икмәк һәм икмәк - күмәч әйберләре** | | | |
| Чистартылган арыш оныннан һәм 1 сортлы бодай оныннан пешерелгән формалы, данәле "Дарницкий" икмәге | 900 г. | 2 - 09 | 2 - 40 |
| Пленкага төрүле шул ук икмәк | | | 2 - 60 |
| Чистартылган арыш оныннан һәм 2 сортлы бодай оныннан формалы, данәле "Славянский" икмәге | 900 г. | 2 - 09 | 2 - 40 |
| Пленкага төрүле шул ук икмәк | | | 2 - 60 |
| Чистартылган арыш оныннан һәм 2 сортлы бодай оныннан пешерелгән формалы, данәле "Деревенский" икмәге | 900 г. | 1 - 91 | 2 - 20 |
| Пленкага төрүле шул ук икмәк | | | 2 - 40 |
| Чистартылган арыш оныннан һәм бодай яралгы укмашларыннан пешерелгән формалы, данәле"Уңыш" икмәге | 900 г. | 1 - 83 | 2 - 10 |
| Пленкага төрүле шул ук икмәк | | | 2 - 30 |
| Татарстан Республикасы Кулланучылар хокукларын яклау дәүләт комитеты белән бәяләрне килештерү беркетмәсенә нигезләнеп, арыш оныннан, һәм башка исемнәрдәге бодай оны катнашмасыннан пешерелгән икмәк | | | |
| 1 сортлы бодай оныннан пешерелгән формалы, данәле ак икмәк | 750 г. | 2 - 43 | 2 - 80 |
| Пленкага төрүле шул ук икмәк | | | 3 - 00 |
| Татарстан Республикасы Кулланучылар хокукларын яклау дәүләт комитеты белән бәяләрне килештерү беркетмәсе нигезендә 1 сортлы бодай оныннан башка исемдәге икмәк һәм икмәк - күмәч әйберләре | | | |
| 2 сортлы бодай оныннан пешерелгән формалы, данәле ак икмәк | 780 г. | 2 - 09 | 2 - 40 |
| Пленкага төрүле шул ук икмәк | | | 2 - 60 |
| 2 сортлы бодай оныннан пешерелгән икмәк һәм икмәк - күмәч әйберләре, бәяләрне Татарстан Республикасы Кулланучылар хокукларын яклау дәүләт комитеты белән килештерү беркетмәсе нигезендә башка исемдәге әйберләр | | | |
| **Ярма** | | | |
| Манный ярмасы | кг | 2-80 | 3-30 |
| **Сөт һәм сөт продуктлары** | | | |
| Флягаларда 2,5 процент майлылыктагы сөт | литр | 1-54 | 1-80 |
| 2,5 процент майлылыктагы сөт (полиэтилен пакетларда) | литр | 1-71 | 2-00 |
| 2,5 процент майлылыктагы сөт (полиэтилен пакетларда) | 0,5 л | 0-94 | 1-10 |
| 3,2 процент майлылыктагы кефир (полиэтилен пакетларда) | 0,5 л | 1-11 | 1-30 |
| 2,5 процент майлылыктагы кефир (полиэтилен пакетларда) | 0,5 л | 1-01 | 1-20 |
| 3,2 процент майлылыктагы катык (полиэтилен пакетларда) | 0,5 л | 1-20 | 1-40 |
| Флягаларда 3,2 процент майлылыктагы "Детское" пастеризацияләнгән сөт | литр | 2-05 | 2-40 |
| 2,5 процент майлылыктагы һәм аннан түбәнрәк майлылыктагы сөтнең, "Детское" пастеризацияләнгән сөтенең, кефир һәм катыкның башка төрләренә бәяләр Татарстан Республикасы Кулланучылар хокукларын яклау комитеты белән килештерелгән беркетмә нигезендә | | | |

**2НЧЕ КУШЫМТА**

## ОННЫ ҺӘМ МАННЫЙ ЯРМАСЫН КҮПЛӘП ҖИБӘРҮНЕҢ ЧИК БӘЯЛӘРЕ (СУМНАРДА)

| Исеме | Үлчәү берәмлеге | Икмәк пешерү промышленностеның бөтен төр милек формаларына ия булган - юридик зат булган икмәк пешерү предприятиеләренә, шулай ук барлык дәрәҗәләрдәге бюджетлардан финанслана торган учреждениеләргә онны күпләп җибәрүнең чик бәясе | | Ваклап сату сәүдәсе өчен продукцияне күпләп җибәрүнең чик бәясе |
|---|---|---|---|---|
| | | **НДСсыз** | **НДС белән** | **НДС белән** |
| Югары сортлы бодай оны | тонна | 1727 | 2072 | 2500 |
| 1 сортлы бодай оны | тонна | 1607 | 1928 | 2200 |
| 2 сортлы бодай оны | тонна | 1067 | 1280 | 1400 |
| Чистартылган арыш оны | тонна | 1058 | 1270 | — |
| Манный ярмасы | тонна | — | — | 2800 |

***Искәрмә: Күпләп җибәрү бәяләре капчык - тараның кыйммәтен исәпкә алмыйча билгеләнде. Капчык - тараның бәясе өстәмә рәвештә түләнә.***

***Министрлар Кабинеты 1998 елның 19 сентябрендә чыгарган карарындаТатарстан Республикасында җитештерелә торган азык - төлек товарларына чик сәүдә өстәмәләре билгеләде (түбәндәге кушымта).***

## ЧИК СӘҮДӘ ӨСТӘМӘЛӘРЕ

| Товарларның исеме | Предприятие - әзерләүченең күпләп җибәрү бәясенә сәүдә өстәмәсенең күләме (процентларда) | |
|---|---|---|
| | **Шәһәр** | **Авыл** |
| 1 һәм 2 сортлы бодай оныннан, арыш оныннан, арыш һәм бодай оны катнашмасыннан пешерелгән икмәк һәм икмәк - күмәч әйберләре | 15 | 15 |
| Манный ярмасы | 18 | 18 |
| 2,5 процент майлылыктагы һәм аннан түбәнрәк майлылыктагы сөт, "Детское" пастеризацияләнгән сөт, кефир, катык | 17 | 17 |
| Татарстан Республикасында җитештерелә торган башка азык - төлек һәм промышленность товар- | 25 | 30 |

***Мәктәпләрдә уку елы бара***

## ЯҢА ИДЕЯЛӘР БЕЛӘН ЯШИБЕЗ

Яңа уку елы башланды гына әле. Без менә алтынчы ел инде аны яңа мәктәптә каршыладык. Мәктәбебез бик матур һәм башкаларга охшамаган килеп чыкты. Беренчедән, ул үзгә проект буенча салынган, икенчедән, мәктәптәге матурлык һәм уңайлыклар укучыларны һәм укытучыларны гына түгел, ата - аналарны да үзенә тартып тора.

Бездә эшләүче укытучыларга, алардагы энтузиазм һәм энергиягә сокланып туя алмыйм мин. Нинди генә идея ташлама, алар аны шунда ук эләктереп алалар һәм, син көткәннән дә уздырып, үзләрендәге фантазияне эшкә җигеп гамәлгә дә ашыралар.

Җәй көне бик күп эшләр эшләргә өлгердек. Агымдагы ремонт ясарга безгә ата - аналар да бик зур булышлык күрсәтте. Үзләренә дә бик авыр булуга да карамастан (авылда инде ике елга якын хезмәт хакы алган юк), күп кенә ата - аналар мәктәпне ремонтлауга 20 - 25шәр сум акча бирергә мөмкинлек таптылар. Класс җитәкчеләре ул акчага буяу, обой сатып алдылар һәм ата - аналар белән бергәләп класс бүлмәләрен яңарттылар. Моңа кадәр андый юлга барганыбыз юк иде, быел менә замана авырлыгы мәҗбүр итте. Безнең гозергә колак салган һәркемгә чиксез рәхмәтебезне белдерәбез. Хәзер мәктәбебез чиста, балкып тора һәм андый бүлмәләрдә балаларга да утыруы күңелле.

Хәзер укытучылар класс бүлмәләрен төрлечә җиһазлау һәм бизәү белән мәшгульләр.

Мәктәп яны бакчасында да күп эшләр башкарылды. Биология укытучысы Н.А.Корнеева һәм хуҗалык мөдире С.Г.Макарова җитәкчелегендә укучылар җәй буе анда эшләп, әйбәт кенә нәтиҗәләргә ирештелер.

Яңа уку елына әзерлек буенча конкурста безнең мәктәп авылныкылар арасында иң яхшысы дип табылды. Ә без тагын да яңарак идеяләр белән яшибез.

**Л.ТРИШИНА,**
**Сәләңгеш урта мәктәбе директоры.**

## Килми калмагыз, күрми калмагыз!



# ВИТАЛИЙ АГАПОВ - НУРЛАТ СӘХНӘСЕНДӘ



***Сентябрьнең соңгы көнендә Нурлат район мәдәният йортында танылган көйләр остасы Виталий Агапов һәм аның концерт төркеменең чыгышы була. Шул хакта белгертергә дип килгән менеджерлары Фирая ФӘХРИЕВА редакциягә дә кереп чыкты һәм без аның белән булачак концерт турында гәпләшеп алдык.***

***- Фирая, Виталий Агаповның кемлеге турында тамашачыга бик озаклап сөйләп торасы юктыр инде. Үзешчән татар композиторларының Бөтенроссия конкурсында дипломант исемен алган Агаповның җырлары үзе башкаруында да, башкалар авызыннан да ишетелеп тора бит...***

- Әйе, биш - алты ел эчендә шундый зур популярлыкка ирешкән үзешчән композиторлар күп түгел. Аның тиз танылып китүенә җырларының (кайберләренең сүзләре дә Виталийның үзенеке) халыкчан рухы, кыланусыз - нисез, ясалмалылыксыз башкарылуы да сәбәптер. Берничә аудио һәм видеокассетасы чыгу үзе генә дә күп нәрсә турында сөйли бит. Аннары, безнең "Моңлы Чаллы" җыр студиясе Виталий җитәкчелегендәге төркемнең чыгышларын кайларда гына оештырмый бит әле. Чиләбе якларында да, Башкортостанда да булдык без,Татарстанның да күп кенә районнарында чыгышлар ясадык. Әле менә Мәскәүгә дә чакырулыбыз. Үзебездә, Чаллыда соңгы концертыбыз җиде көн рәттән барды һәм көн дә зал тулы иде.

***- Сезнең концертка килгән Нурлат тамашачысына үкенергә туры килмәячәк алайса?...***

- Концертларыбыз һәркайда зур уңыш белән уза. Виталийның аларны үзе үк уен - көлке белән, тамашачы белән ике арада "җылы" күпер салып алып баруын да бик ошата халык, ә инде аның ягымлы тавышлы җырлавын әйткән дә юк. Былтыр аның Мирһади Разов сүзләренә язган "Әнкәй гөле" дигән җыры Татарстандагы иң популяр ун җыр арасына кертелүе дә тамашачының Виталийга булган мәхәббәте турында сөйли бит. Соңгы концерт программабыз да шул җыр исеме белән аталган. Ә инде беренче булып безнең җырчы кызыбыз Лилия Кәлимуллина башкарган "Барам синең яннарыңа" дигән җырның ничек популярлашып китүе турында аның, сүзләрен үзгәртебрәк төрле төбәкләргә багышлап та башкарылуы гына да ачык сөйли.

***- Сүз чыккач, коллективның башка артистлары турында да әйтеп китик инде...***

- Виталий гел үзе генә җырлап тамашачыны ялыктырырга тырышмый. Аның концерт төркемендә бик матур тавышлы җырчы кызлар да, егетләр дә бар, биючеләребез дә сәхнәдә бөтерчек кебек әйләнәләр. Концертыбызның баянчысы Ринат Абдуллинның үзе уйнап җырлавын да тамашачы бик җылы кабул итә. Инде тамашачыга билгеле Эльвира Тимергалинабыз янына тагын бер җырчы кыз Индира Сәлимова өстәлде. Һәркайда сәхнәгә кабат чакырып чыгарып җырлаталар үзләрен. Ә инде сәхнәгә биючебез Андрей Павловский чыкса, тамашачы урыныннан кубардай булып алкышлап утыра...

***- Ярар, Фирая, барысын да сөйләп концертның кызыгын бетермик әле. Тамашачыга 30 сентябрь кичендә матур җырлар, биюләр һәм нәфис сүздән күп сюрпризлар алырга да урын калдырыйк.***

- Әйе шул, концертыбызның <u>кичке сәгать җидедә</u> башланып, ике сәгать ярым барасын гына әйтик тә... Билетның <u>15 кенә сум</u> булуын да белеп торсыннар тагын.

**Р.ГЫЙЛЬМЕТДИНОВ**
**сөйләште.**

## СПОРТ • СПОРТ



### ТИЗДӘН - ФИНАЛ ОЧРАШУЫ

Ир - атлар арасында футбол буенча район кубогына ярышлар дәвам итә. Кубок өчен көрәш 6 команда арасында барды. "Зүзәйнефть" командасы Каравыл Тавы һәм Богдашкино командаларын отып, финалга чыкты. НУРБ "Нефтянигы" - "Нурлатнефть" НГДУсы һәм шикәр заводы командаларын җиңеп, финалга үтте.

Финал уены кызыклы булырга охшый: командаларның көче тигез диярлек. Ул 26 сентябрь көнне 14 сәгатьтә булачак. Футбол сөючеләрне шәһәр стадионында көтәбез.

**Х.ФАТУЧЕВ.**

### ФУТБОЛНЫ ЯРАТАЛАР

Каравыл Тавы авылы футболчылары менә күп еллар инде район ярышларында даими катнашып киләләр. Уйнап кына калмыйлар, күбесенчә призлы урыннарга да чыгалар. Кайда гына уйнасалар да, футболчылары өчен бар авыл җан атып тора. Менә бу җәйдә дә, авырлыкларга да карамастан, команда уйнарга җай тапты. Район беренчелегенә ярышларда Каравыл Тавы егетләре икенче урынга чыктылар. Футбол ветераннары Николай Олопов, Петр Волков, бертуган Матвеевлар, Борисовлар һәм Кадяшевларның, Федоров, Волков, Арбузов, Ефимчук, Майоровның... зур уңышы дип карарга кирәк моны. Булдырасыз, егетләр, диясе килә.

Бер үк вакытта футболчыларның хәленә кергән хуҗалык җитәкчелегенә дә, егетләрнең тарафдарларына да рәхмәт зур.

**С.ГРАФ.**

## БЕЛДЕРҮЛӘР, РЕКЛАМА, БЕЛДЕРҮЛӘР

### САТАБЫЗ


**Некрасовкада дача.** Тел.: 5-22-67, кичке 4тән соң.

***

**ПМК - 547 ягында базы белән капиталь гараж.** Тел.: 5-38-40.

***

**Бик әйбәт хәлдәге ВАЗ - 21099.** Адрес: К.Маркс пр., 3 - 9, тел.: 5-32-80.

***

**СПТУ микрорайонында особняк.** Тел.: 2-17-00, кичке 7дән соң.

***

**3 бүлмәле фатир, 3нче кат.** Тел.: 5-21-04, кичке 6дан соң.

***

**Лобачевский урамындагы 58 нче йорт.** Куйбышев ур. 78 - 1 адресы буенча кичке 5тән соң мөрәҗәгать итәргә.

***

**Аерым - аерым силикат кирпеч, газобетон, кыйммәт түгел.** Якушкинода Л.Максюткинага мөрәҗәгать итәргә.

***

**Абрыскинода йорт, чистарту корылмалары ягында төзелеп бетмәгән гараж (1,5 мең).** Адрес: Дружба ур., 69 - 6.

***

**160х130лы 4 мм.лы пыяла.** Адрес: Төзүчеләр ур., 35-5, кичке 4тән соң.

***

**Туй күлмәге, кыйммәт түгел.** Тел.: 5-32-01.

***

**Кулланылышта булган телевизор һәм ус җайланмасы.** Тел.: 5-29-66.

***

**Керамзит блоклар, илтеп бирәбез.** Түбән Камада тел.: 35-66-12, 31-08-52.

### САТАБЫЗ ЯКИ АЛМАШТЫРАБЫЗ

**Өйнең яртысын (6 сутый участогы бар). Яки бер бүлмәле фатирга алмаштырабыз.** Адрес: Декабристлар ур., 11.

### АЛМАШТЫРАБЫЗ ЯКИ САТАБЫЗ

**Особняктагы 2 бүлмәле фатирны - өстәмә түләп 3 бүлмәлегә. Яки сатабыз.** Адрес: Космонавтлар ур., 33 - 2.

### САТЫП АЛАМ

**Бер бүлмәле фатир.** Тел.: 2-20-38, кичке 6нчы яртыдан соң.

### ТӨРЛЕСЕННӘН

**Төзүчеләр турында бушлай мәгълүмат бирәм. Сыйфатлы итеп йортлар, гаражлар, янкормалар салалар.** Тел.: 5-16-25, Нәҗип.

***

**1 - 2 көндә язып биреп мәрмәр кыйпылчыгыннан кабер ташлары, гранитта портретлар ясап сатам. Бәяләр искечә.** Адрес.: Ленинград ур., 14.

***

**Сатучылыкка эш эзлим, вариантлар мөмкин.** Тел.: 2-20-75, кичке 3тән соң.

***

**Колыны белән, кара төстәге, йолдызсыман кашкалы 6 яшьлек ат югалды. Аның кайдалыгын белүче булса, бүләк бәрабәренә Чулпанда Вәгыйзь Гобәйдуллинга хәбәр итүләрен сорыйбыз.**


## * 02 ХӘБӘР ИТӘ * 02 ХӘБӘР ИТӘ * 02 ХӘБӘР ИТӘ *

### ТӘГӘРМӘЧ ЧАБАТАСЫЗ ТӘГӘРӘМИ ШУЛ...

Элек хөкемгә тартылган К. һәм аның "кулдашы" Т. өчен ул төн яртылаш кына уңышлы булып чыга. Бөгелмәдәге бер оешманың Нурлатта 1 нче ПМК территориясендәге складыннан урланган авторезинаны ничек төшемлерәк урнаштыру турында уйлап кына барганда, аларның арткы урындыкларын да алып товар тутырылган "Жигули"ен милициянең патруль төркеме туктата. Шунда ук 18 авторезина алына, ә тагын 5 резинаны һәм өч капчык шикәр комын ерак түгел генә яшереп куйган булалар. Һәм юкка гына вакыт әрәм итеп йөргәннәр икән шул. Урланган барлык мал кире кайтарыла, хуҗаларга да моннан ары ныграк сакланырга кушыла.

### ҮЧЛЕ ӨЧ БЕРТУГАН

Ә менә Мамык авылындагы туганнары К.га булган үпкәләрен шәраб ачысы белән дә кыздырып җибәргән бертуган С.лар аны акылга утыртырга дигән ният белән төнге икедә өенә бәреп керәләр. Шаһитләр күзеннән ераграк булу максатыннан алар аны "КамАЗ"га утыртып кырга алып китәләр, әмма К. тегеләр кулыннан ычкына, ә үч алырга ниятләгән өч бәндәне ( берсе - Чирмешәннән, икенчесе- Яңа Чишмәдән, өченчесе - Мамыкныкы) эчке эшләр бүлегенең дежур төркеме тота. Җинаять эше кузгатылды.

### УЙЛАНАЛАР МИКӘН СОҢ?..

Шәхси машиналарны әрчеп кинәнү - шәһәрдәге кайбер үсмерләрнең бик яраткан шөгыле. ( Аларның кайсылары Җинаять Кодексының аерым маддәләре белән дә бик яхшы таныш инде). Кайберәүләрнең үз машиналарын уйламый - нитми генә ишегалларында калдыруын белгән ул үсмерләр, машиналардан магнитофон, көзге ише җиһазларны, тәгәрмәчләрне салдырып алырга, бензиннарын агызып алырга бик күнегеп китәләр. Урланган әйберләрне алар таныш һәм таныш булмаган кешеләргә арзан хакка саталар да, шул акчага аракы, сигарет сатып алалар һәм... Әле менә район эчке эшләр бүлеге хезмәткәре ике яшүсмер С. һәм Е.ны шундый гамәл вакытында тоткарлый. Малайларга җәза каралган каралуын, ә менә аларның әти - әниләре улларының төннәрен кайда йөрүләре белән кызыксына микән соң?

### ҺӨҖҮМ ИТҮЧЕЛӘР... МИЛИЦИЯДӘН БУЛЫП ЧЫККАН

Самара өлкә эчке эшләр идарәсенең патруль - пост службасының ике хезмәткәре аркасында Биляр Озеродан КамАЗ шоферы һәм "Полесье" тракторчысы каза күргән. Кызып алган сержантлар һәм аларның туганы төнлә Кармалага китеп бармакчы булалар һәм шул максаттан КамАЗ машинасына күз салалар. Ә инде шофер да, тракторчы да аларны илтүдән баш тарткач, тегеләр КамАЗ кабинасына бәреп кереп, икесен дә кыйный башлыйлар. Шофер Кошки районы территориясендә кабинадан ничек кирәк алай сикереп төшеп кала, ә тракторчы берничә сәгатьтән генә аңына килә. Нурлат эчке эшләр бүлеге хезмәткәрләре тегеләрнең кем булуын ачыклаганнар,һәм җинаять эше кузгатылган.

## Булмас димә, дөнья бу!

### МАРСТА СУ БАРМЫ?

Галимнәр әле күптән түгел генә Марс планетасын янар таулар эссесеннән торган ут шары дип табалар иде.



Соңгы елларда үтә сизгер приборлар ярдәмендә алынган күпсанлы фотолар моның нәкъ киресен исбатлады. Галимнәр уйлавынча, Марста су исәпләгәннән дә 100 тапкырга артыграк икән. Андагы су эчәргә һәм аш пешерергә генә түгел, кислород бүлеп чыгару гамәлендә дә катнашырга җитәрлек күләмдә икән.

**("Юлдаш"тан)**

МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА.**


**Учредительләр:Нурлат район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.**

**"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**

**Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Нурлат шәһәре, Карл Маркс урамы,19. Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм җаваплы сәркәтип - 2-18-67, авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар, хатлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия,реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.**

***ГазетаТатарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.***

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясендә офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2361 данә. 4001